СОВЕТ
СТАРОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Тукая, д. 2, с.Нижние Метески,
Арский муниципальный район, 422022

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Тукай урамы, 2 йорт, Түбән Мәтәскә авылы,
Арча муниципаль районы, 422022

Тел. (84366)56-2-93, факс (84366)56-2-93. E-mail: Kuper.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча районы**
**Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы карары**

**22 март 2024 ел** **N 1**

**«Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Иске Иябаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Иске Иябаш авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге уставының 25 статьясына ярашлы рәвештә, Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирде:

1. « Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Иске Иябаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Иске Иябаш авылы, Муса Җәлил урамы, 41А йорт , Иске Иябаш КФҮ адресы буенча 2024 елның 05 апрелендә 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. « Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Иске Иябаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Иске Иябаш авылы, Муса Җәлил урамы, 41А йорт , Иске Иябаш КФҮ адресы буенча 2024 елның 05 апрелендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Халык исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

1 нче этап: Муса Җәлил урамы халкы

2 нче этап: Яшьләр урамы, Яшел урам,Татарстан урамы  халкы.

4. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Иске Иябаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 22 ноябрендәге  1 номерлы  карарында гражданнар җыены соравын яңа редакциядә бәян итәргә:

Сез 2024 елда Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Иске Иябаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум, көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, 75 яшьтән узган  гражданнардан 150 сум күләмендә үзара салым кертелүгә, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, ире яки хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итәргә һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына  ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл-урам челтәренә нигез салу һәм вак таш белән каплау Иске Иябаш  авылы, Татарстан урамы)?

«ӘЙЕ»  «КАРШЫ»

5. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Кырлай авыл җирлегенең Иске Иябаш авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның  22 ноябрендәге  1 номерлы  карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Иске Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны ТР, Арча районы, Иске Иябаш авылы, Муса Җәлил урамы, 41А йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru  һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan ru веб-адреслары буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Иске Кырлай авыл җирлеге башлыгы  Ф.Ф.Лутфуллин

СОВЕТ СТАРОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ